ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.10.2023 ел Баулы шәһәре №188

2024 елда Баулы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын бушлай туклану белән тәэмин итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, СанПИНның 2.4.5.2409-08 «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» таләпләрен үтәү максатларында сәламәт туклануны оештыру, шулай ук аерым категория укучыларга өстәмә социаль ярдәм чараларын күрү өчен Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2024 елда бушлай туклану белән тәэмин итәргә:

- бер үк вакытта Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы 4 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күп балалы гаиләләрдәге балаларны;

- Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы, «Баулы муниципаль районында «Гаилә» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют» ДКУсы балаларын;

- Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы инвалид балаларны.

2. Баулы муниципаль районның финанс-бюджет палатасына, 2024 елда җирле бюджетны үтәү процессында, гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга бушлай туклануны тәэмин итү буенча ташламалар бирү чараларына чыгымнарны каплау өчен финанс чаралары эзләргә.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге” МКУ начальнигы Д,З Ганиевага, «Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмати системасы турында» 2021 елның 16 августындагы 1342 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карарына ярашлы тәртиптә һәм күләмдә әлеге карар белән билгеләнгән, Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында бер үк вакытта белем алучы 4 һәм аннан да күбрәк баланы тәрбияләүче күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары күрсәтү хакында ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар белән, мәгълүмат җиткерүне (урнаштыруны) тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров